СОВЕТ НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«21» сентябрь 2020 ел № 8

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләр белән), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2014 елның 29 ноябрендәге 110-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2020 елның 24 июлендәге ачык тыңлаулар нәтиҗәләре, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе бәяләмәсе нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Норма авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә.
4. Әлеге карар рәсми халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.
5. Уставның 88 статьясындагы 3 пунктының (бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләү сроклары өлешендә) гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатылды.
6. Үзгәрешләр кагылышлы 15.1, 16, 22, 23.1, 24.1, 85.1 статьялар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә. Уставның 15.1 һәм 85.1 статьялары нигезләмәләренең гамәлдә булуы әлеге карар үз көченә кергән көнгә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылмый.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгы Р. Н.Шәрипҗановка йөкләргә.

Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов